**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Югары Налим авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 119** **07.12.2018**

**«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, җирле үзидарә органнары белгечләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 93 номерлы Югары Налим авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. « Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, җирле үзидарә органнары белгечләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 93 номерлы Югары Налим авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.11 пунктчасында «38,75» санын «56» санына алмаштырырга.

2. «Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы

вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә, җирле үзидарә органнары белгечләренә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 24 апрелендәге 93 номерлы Югары Налим авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 24 ноябрендәге 117 номерлы Югары Налим авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Югары Налим авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2018 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Ф.Н. Николаева**